КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 20 июнь г.Казань № 588

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче гражданнарның аерым категорияләренә торакка һәм коммуналь хезмәтләргә түләү буенча социаль ярдәм күрсәтү чаралары турында» 2005 ел, 20 апрель, 192 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче гражданнарның аерым категорияләренә торакка һәм коммуналь хезмәтләргә түләү буенча социаль ярдәм күрсәтү чаралары турында» 2005 ел, 20 апрель, 192 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 7 июнь, 251 нче; 2006 ел, 24 апрель, 209 нчы; 2006 ел, 15 июнь, 308 нче; 2007 ел, 5 февраль, 35 нче; 2008 ел, 29 май, 344 нче; 2014 ел, 13 февраль, 83 нче; 2017 ел, 1 ноябрь, 833 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1228 нче; 2019 ел, 16 июль, 588 нче, 2020 ел, 23 ноябрь, 1053 нче, 2021 ел, 03 февраль, 47 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), $1^1$ пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәп, үзгәреш кертергә:

«Әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән гражданнар гаризасы буенча җылыту сезоны чорында торак урыннар, җылылык һәм яктырту өчен түләү чыгымнарын компенсацияләү беркетелгән күләмдә 1 200 сум күләмендә бирелергә мөмкин.

Торак урыннар, җылылык һәм яктырту өчен түләү чыгымнарын компенсацияләү билгеләнгән әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән гражданнар агымдагы елның 1 сентябренә кадәр җылыту сезонында аның күләмен сайлау турында гариза бирә ала, ул күрсәтелгән гаризаны 1 сентябрьдән алып

1 сентябрьгә кадәр тапшыра, анда гражданин ягулык сезонында алына торган торак урыннар, җылылык һәм яктырту өчен түләү чыгымнарын компенсацияләү күләмен сайлау турында яңа гариза белән мөрәҗәгать итәчәк.».

2. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына әлеге карарны гамәлгә ашыру өчен кирәкле «Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасын эшләп бетерүне тәэмин итәргә.

3. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

бу карар, әлеге карарның 2022 елның 1 ноябреннән үз көченә керә торган 1 пунктынна тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә;

2022 елда гражданнар 1 декабрьгә кадәр торак урыннар, җылылык һәм яктырту өчен түләү чыгымнарын компенсацияләү күләмен сайлау турында гариза бирә ала.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин